ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.02.2025 Олы Кайбыч ав. № 46

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Коланҗы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында

Халыкның тормыш эшчәнлегенең уңай шартларына хокукларын, җир кишәрлекләре хокук ияләренең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Коланҗы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Коланҗы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге генераль планы проекты буенча гавами тыңлауларны 2025 елның 24 февралендә 10.00 сәгатьтә Кайбыч районы, Коланҗы тимер-юл станциясе поселогы, Шоссе урамы, 30 нчы йорт адресы буенча урнашкан Коланҗы күпфункцияле үзәгендә үткәрергә.

3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Коланҗы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге генераль планы проектындагы материаллар (текстлы һәм график өлеш) белән эш көннәрендә 800 сәг тән 17.00 сәг кә кадәр Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2нче кат, 209 нчы кабинет адресы буенча урнашкан Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегендә танышырга мөмкин.

3.1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Коланҗы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге генераль планы проектына кагылышлы тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гавами тыңлауларда катнашучылар тарафыннан кертү урыны итеп Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2 кат, 209 нчы кабинет адресы буенча урнашкан Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеген һәм Коланҗы тимер-юл станциясе

поселогы, Шоссе урамы, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан Колаңгы авыл җирлеге Советы һәм башкарма комитеты бинасын билгеләргә.

4. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә:

- Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Колаңгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга;

- әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча урынбасары Е.Г. Давыдовага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров